СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
13 август 2018 ел

Карар
№ 4-31

**«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге № 97-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектын хупларга. (1 нче кушымта).
2. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча Ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен расларга. (2 нче кушымта).
3. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча Гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).
4. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча Ачык тыңлауларны 2018 елның 3 сентябрендә Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитетының административ бинасының утырышлар

залында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Мамадыш муниципаль районы, Көмеш-Күл авылы, Үзәк урамы, 98 йорт.

5. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Сәләхетдинов Илгизәр Нуретдин улы – 4 нче номерлы бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем җитәкчесе;

2) Фәсхиев Рәмис Әхмәтгали улы – 1 нчы номерлы бермандатлы сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Кашапова Дания Тахир кызы– 6 нче бермандатлы сайлау округы депутаты, төркем әгъзасы.

6. Эшче төркемгә 2018 елның 7 сентябренә кадәр «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектына карата кергән гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, аны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны 2018 елның 14 августына кадәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга(халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Башлык,
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы рәисе И.Н.Сәләхетдинов

Мамадыш муниципаль районы Кѳмеш-Күл авыл җирлеге Советының 13.08.2018 ел, № 4-31 карарына 1 нче кушымта

1. «Гражданнар җыены» 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. «Гражданнар җыены халык тарафыннан турыдан-туры җирле үзидарәне гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы формасы булып тора.

2. Гражданнар җыены «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очракларда һәм җирлек советы раслаган «Җирлек составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» Нигезләмә нигезендә үткәрелә. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) авыл җирлеге (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча торак пунктта күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район)территориясенә кертүгә китерә торган күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

2) җирлек Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә әлеге җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

3) җирлек Советы вәкаләтләрен башкара торган җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия кешеләр саны 100 дән артык булса, җирлек советын төзү, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турындагы мәсьәлә буенча;

4) авыл җирлеге Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

5) җирлек составына кергән торак пунктта, шәһәр эчендәге районда, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округында яисә муниципаль район чикләрендәге авылара территориядә урнашкан, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын алга этәрү максатларында, авылара территориядә урнашкан торак пунктта;

7) халык тыгыз урнашмаган, яки барырга кыен булган урында унашкан Җирлектә, Җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча, әгәр бу җирлектә яшәүчеләр саны 100 дән артмаса;

8) авыл торак пунктында авыл торак пунктының старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

9) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

4. Гражданнарның җыены Җирлек башлыгы тарафыннан йә сайлау хокукына ия, кимендә 10 кеше яши торган торак пунктта яшәүчеләр төркеме инициативасы белән чакырылырга мөмкин.

5. Җыен үткәрү инициативасын хуплау йөзеннән җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия, торак пункт территориясендә даими яки нигездә яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин 25тән дә ким була алмый.

6. Җирлек башлыгы чакыра торган халык җыены җирлек башлыгы карары белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән билгеләнә.

7. Торак пунктта яшәүчеләргә халык җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итәләр, халык муниципаль хокукый акт проекты һәм гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан ук «Җирлек составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә танышалар.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

Мамадыш муниципаль районы Кѳмеш-Кѳл авыл җирлеге Советының 13.08.2018 ел,
№ 4-31 карарына
2 нче кушымта

# «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

(муниципаль берәмлек уставы һәм «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә»)

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча (алга таба - ачык тыңлаулар) ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә үткәрелә.
2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен ачык тыңлауларда катнашучылар булып ачык тыңлаулар уздыру датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча язма гариза биргән затлар тора.
3. Халык тыңлауларында халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган кешеләре дә катнаша ала.
4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.
5. Тыңлауларда җирлек башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Җирлек башлыгы урынбасары, җирлек башлыгы вәкаләтләре бирелгән башка затлар катнаша ала.
6. Халык алдында тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне исәпкә алу өчен рәис тәкъдиме буенча ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.
8. Чыгышларның эзлеклелеге һәм вакыты, карала торган мәсьәләнең эчтәлеген, ачык тыңлауларда катнашу өчен кергән язма гаризаларның санын һәм башка мәсьәләләрне исәпкә алып, ачык тыңлаулар уздыру регламенты белән билгеләнә.
Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин.

9. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.
10. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.
11. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәп куела.

12. Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче имзалый һәм ул җирлек Советы материаллары белән бергә саклана.

Башлык,
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы рәисе И.Н.Сәләхетдинов.

Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл
авыл җирлеге Советының 13.08.2018 ел, № 4-31 карарына
3 нче кушымта

# «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ «МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА КАРАТА ГРАЖДАННАР ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ АНЫҢ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУЫ ТӘРТИБЕ

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча тәкъдимнәр Көмеш-Күл авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422147, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Көмеш-Күл авылы, Узәк ур., 98 й. адресы буенча (885563) 2-46-38 тел./факс, e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru буенча язмача формада Ф.И.А.и туу датасын күрсәтеп түбәндәге таблицада тутырылып җибәрелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проектының тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адрес, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр әлеге карар игълан ителгән көннән алып эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

1. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: 422147, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Көмеш-Күл авылы, Үзәк ур., 98 й, шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «Ачык тыңлаулар» тамгасы белән), шулай ук телефон / факс (885563) 2-46-38 e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, буенча.

   Гаризалар ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Көмеш-Күл авыл җирлеге Советына һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

Башлык,
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы рәисе И.Н.Сәләхетдинов